**ЙӨРӘК ТИБЕШЕ**
**Данис Хәйруллин**
**иҗатына багышланган әдәби композиция**
*(8-9нчы сыйныф укучылары өчен)*

*Кичәнең башыннан ахырынача талгын гына көй агыла,*
*ике алып баручы чыга.*

**1нче алып баручы**:

Менә – кәгазь!
Менә – каләм!
Язылыр сүз – минем фикер!

Торам уйлап, озак карап:
Кайсы чыдар озаккарак?
Бер саргаер бу кәгазь дә,
Бер җуелыр каләм эзе.

Ил теленә күчәрлекме,
Канатлымы әйтер сүзем?
Җуелмасмы, саргаймасмы
Фикер-уем – баймы, саймы?
Ак биләвен кулга тоткан,
Бала көткән анадай мин.

*«Язу»*

**2нче алып баручы**: Исәнмесез, шигърият сөюче дуслар! Бүген кичә дәвамында без Эдуард Касыймов исемендәге премия лауреаты, «Мәдәнияттәге казанышлары өчен» билгесе иясе, Татарстан Язучылар берлеге әгъзасы, шагыйрь Данис Хәйруллинның иҗаты турында сүз алып барырбыз, шигырьләрен ишеттерербез.

**1нче алып баручы**:

Сабый йоклый.
Уч төбендә
Тамчы-тамчы кояш яна.
Чәчәк таҗы кебек куллар –
Язмыш ниләр язган аңа?
Үсмер бала.
Куенында
Чагылмаган чакма ташы.
Җиткән егет.
Кулларында
Күмерләнгән шырпы башы.
Һәм, ниһаять солдат менә –

Бармакларда дары исе.
Ир баланың язмышына
Язылгандыр ялкын төсе.

*«Ир бала»*

**2нче алып баручы**:

Бу йөрәктә нинди эзләр соң бу?
Арта гына бара гел яшәп.
...Һәр картлыкта сүнә кичәге көн,
Һәр сабыйда балкый киләчәк.
Ул балкыш бит киткәннәрнең нуры,
Кабыну юк, сүнү булмаса!
Янумыни яну йөрәгеңә
Үткәннәрнең гамен уймасаң.
Бу йөрәктә нинди хисләр соң бу?
Күнегә алмыйм ничә ел яшәп.
Күзләремнән сынап карый миңа
Чал Тарих һәм сабый киләчәк.

*«Йөрәгеңне ачып сал!»*

**1нче алып баручы**: Шагыйрь, тау астыннан үзенә юл тапкан моңлы чишмәне хәтерләтеп, тын гына иҗат итә. Данис Хәйруллинның шигырьләрен укыган, китапларын кулына төшергән һәркем үзенә рухи ләззәт таба.

**2нче алып баручы**: Данис Хәйруллинның беренче шигырьләре матбугатта 1979 елдан күренә башлый.

Бүгенге көндә аның «Хәтер» (1988), «Йөрәк тибеше» (1991), «Казлар ник көлә?» (2011) китаплары дөнья күрде.

*Укучылар чыгышы.*

**1нче укучы:**

Сулар ага да ага,
И бәхетле бу бала!
Кәгазь көймәгә төреп
Агыза вакыт көлен,
Аңламый сәгать телен.

*«Сәгать телендә...»*

**2нче укучы:**

Сөенегез, күргән, белгән!
Кояш күккә байрак элгән,
Күпер салган аллы-гөлле.
Каршы ала дисез кемне?
Гөлләр белән җитәкләшеп,

Күккә тургай моңы чәчеп,
Нечкә билле һәм гаҗәеп
Җәй килә, җәй, колач җәеп.

*«Сөенегез...»*

**3нче укучы:**

Изгелек ул – Идел кебек олы,
Изгелек ул – кояш кебек җылы,
Изгелек ул – мәхәббәттәй сылу,
Мең сырхауга дәва бер изгелек кылу.
Изгелекне алып, биреп булмый;
Изгелекне чәчеп, урып булмый.
Изгелек ул – җирдә яшәү төсе,
Тоя аны изгелекле кеше.

*«Изгелек»*

**4нче укучы:**

Аклыкка табындым мин дә:
Ак дөньяга туган бала
Ак биләүгә төреләә бит,
Аналарның ап-ак кулы
Ак чәчәккә үреләә бит.
Аклыкка табындым мин дә:
Ничә тапкыр туган йортны
Төштә күрдем гел бер килеш:
Чал чәчләрен тарап әбкәм
Ак намазлык җәя, имеш.
Бүген җирдә аксыл томан,
Аклыкны аңламый торам.
Ак кәфендә ята әбкәм,
Ә дөнья кап-кара сыман.
Аклыкка абындым мин дә...

*«Аклык»*

**5нче укучы:**

Урман. Тып-тын
Чү! Җил туды тик бер йотым:
Яфраклардан йөгереп үтте,
Чәчәкләрнең күзен үпте
Һәм сарылды иренемә.
Телгә күчте яфрак тәме,
Күзгә күчте чәчәк чыгы.
Мәңге истә калыр инде
Җәйнең шушы кыйпылчыгы.

*«Мизгел»*

**1нче алып баручы**: Данис Хәйруллин –сизгер шагыйрь. Ул яфрак өзелгәндә агач сызлавын, кара болыт узганда күкнең боегуын, кояш нуры сынуын, бөреләрнең күзләре ачылуын һ.б.ларны образлы күрә белә.

**2нче алып баручы**: Данис Хәйруллинда Аллаһ тарафыннан салынган шагыйрьлек ярылып ята. Шулай булмаса, тимер-томыр арасында хезмәт көнен уздырган көенә шигырьләр иҗат итә алмас иде. Ул күп еллар КамГЭСның төзелешне механикалаштыру идарәсендә краннар бүлеген җитәкли. Тупас тимер дә шагыйрьнең нечкә күңеленә тәэсир итә алмаган.

**1нче алып баручы**:

Җил дә исми, тын да түгел:
Болытлар агышымы,
Һаваларга сеңеп калган
Киек каз тавышымы;

Гамь булыпмы, ямь булыпмы,
Әллә үрелеп бергә,
Оя-оя болытлардан
Көзге моң ага җиргә.

*«Көзге моң»*

**2нче алып баручы**:

Бер тамчы чык эчте чыпчык –
Сусавы басылды.
Тамчы чыкта коенды гөл –
Керфеге ачылды.

Бер тамчы яшь күзне юды.
Йөрәк тойды: кош – каурыен,
Гөл – чәчәген
Җиргә койды.
Салкын җилләр исеп куйды...

*«Бер тамчы чык... »*

**1нче алып баручы**: Данис Хәйруллин поэзиягә җитлеккән шигырьләре белән килде. Алар барыннан да элек лирик җылылык белән сугарылган, фикер, тема киңлеге, үткенлеге белән аерылып торалар. Барысы да туган илгә, туган җиргә, гүзәл табигатькә, халык язмышына, иптәшлек, дуслыкка багышланганнар.

*Укучылар чыгышы.*

**1нче укучы:**

Җиләк тә җиләк, диләр.
Ә мин балан яратам:
Һәр куакта ничә кояш!
Һәр тәлгәштә яңа таң!
Җәйләрҗылысын сала да
Көзләрнең салкынына.
Әйләнә көзге учакның
Иң гүзәл ялкынына.
Кырауларга каба-каба
Яна бит ул – күр әнә!
Көзләргә көлеп керергә
Мин баланнан өйрәнәм.

*«Балан»*

**2нче укучы:**

Мин тудым да күзне генә ачтым –
Карамачы утка, диделәр.
Талпындым да тәпи генә бастым –
Җирдән аерып кулда чөйделәр.
Сусадым да тамчы чыклар эчтем –
Ярамый дип күкрәк бирделәр.
Ирек эзләп биләүләрем чиштем –
Тыгызрак итеп төрделәр.
Тел ачылып бер сүз генә дәштем –
Алай түгел болай, диделәр.
Мин наз көтеп күпме сыктым яшем –
Елмайганда алып сөйделәр.
И дөньяның гаҗәп кануннары,
И тормышның кысан иреге...
Мин кабатлыйм шул ук алымнарны -
Җир гаменә баткан ир-егет.

*«Мин тудым... »*

**3нче укучы:**

Бу халкым нигә моңлымы?
Җырларын җырлап кара!
Тарихта аз булганмы ул
Яра өстенә яра.
Бу халкым нигә дәртлеме?
Биюен биеп кара!
Рухы югары булганны
Күкләр күтәреп ала.
Моң да, дәрт тә, дәрман да бар –
Зур халкым, горур халкым.
Кагылма безнең тарихка

Йөрәгең булса салкын.

«Бу халкым... »

**4нче укучы:**

Биектә-биектә ак каурый торналар
Күкләрне иңрәтеп еракка юл ала:
«Канатлар каерылу, илләрдән аерылу,
Һай безнең язмышка язылган шул алар».

Биектә-биектә ак каурый торналар,
Күңелне сагышка салучы моң алар:
«Җитте лә көзебез, күтәрде күгебез,
Киерелде канатлар, тарайды дөньялар

*«Торналар»*

**5нче укучы:**

Атлар кайта, атлар! Офыкларга
Сибелешеп кала яллары.
...Буын-буын башын салды халкым,
Тик атлары йөгән салмады.

Атлар кайта, атлар! Сыный картлар
Аргамакка менгән буынны:
Адаш булып кына тумаганмы,
Алмаш булыр өчен тудымы?

Атлар кайта, атлар! Мәйданнарга
Суырылып керә яшь тайлар;
Чабышлардан ирләр булып кайта
Ат ялына яткан малайлар.

«Сабан туенда»

**1нче алып баручы**:Шагыйрь Данис Хәйруллин 1946 елның 7нче октябрендә Азнакай районы Татар Шуганы авылында туа. 1953-1960 елларда туган авылы җидееллык мәктәбендә укып, 1964 елда шул ук районның Чалпы урта мәктәбен тәмамлый һәм, Казанга килеп, химия-технология институтына укырга керә. Бер елдан Казан авыл хуҗалыгы институтына күчеп, аны 1969 елда авыл хуҗылыгы инженеры-механигы дигән диплом белән тәмамлый. 1969-1970 елларда Совет Армиясе сафларында хезмәт итә.

**2 нче алып баручы**:1972елдан Чаллы шәһәрендә яшәп иҗат итә. Данис Хәйруллин – 1992 елдан Татарстан Язучылар берлеге әгъзасы.

Ул табигать кочагында, хезмәт кешеләре арасында үсә. Яшел болыннар, дулкыннар кагып утыручы бодай басулары, кызарып таң ату, моңаеп кына кояш баюлар – аның күңелен шигъри дулкыннарга этәрә.

Тарих гадел, вакыт – судьядырда,
Хәтерләрнең бар шул үз кануны.
Нигезендә яткан һәрбер таштан
Сыгылып чыга сыман татар моңы.

*«Тарихка бер караш»*

**1нче алып баручы**:

Мин яшим!
Мин бит кеше!
Мин дә кешелек җимешенең
Тузан кебек бер төше.

**2нче алып баручы**:

Күрәм, тоям, сизәмен мин,
Куркамын һәм куркытам.
Яшәү өчен үз чиратым –
Чәчәк гизәм, ут йотам.

**1нче алып баручы**:

Очам-кунам, янам-туңам,
Көнләштерәм, көнлимен;
Сагыштан саргаям,
Уйдан
Уттай кабынам, дөрлимен.

Мин яшим!
Мин бит кеше!
Чагыла миндә табигатьнең
Һәр халәте, һәр төсе.

*«Мин яшим»*

**2нче алып баручы**: Данис Хәйруллин искиткеч сабырлыкка ия кеше. Ул үзенең тормышына рәхмәтле, иҗатта янып яшәве белән бәхетле. Кеше булып яшәве өчен горурлык хисләре кичәрә, үткән көненә, киләчәгенә үкенми яши белә.

**1нче алып баручы**:

Килер бер көн,
Үкенмим мин узганнарга:
Гөл булырмын өзгәннәргә,
Шәфәкь булып яначакмын
Кара төнгә кергәннәргә,
Чишмә булып агачакмын
Бәхет сусап йөргәннәргә.

**2нче алып баручы**:

Килер бер көн,
Үкенмим мин узганнарга.
Уралырмын, югалырмын
Ак хәтердәй бураннарда.

«Өмет»

**Файдаланылган әдәбият**

Хәйруллин, Д. Хәтер: шигырьләр / Д. Хәйруллин. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1988. – 88 бит.

Хәйруллин, Д. Йөрәк тибеше: шигырьләр / Д. Хәйруллин. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1991. – 96 бит.

Хәйруллин, Д. Казлар ник көлә?: шигырьләр / Д. Хәйруллин. – Чаллы: «Диамант» нәшр., 2011. – 38 бит.

Журналның Данис Хәйруллин иҗатына багышланган махсус саны // Мәйдан. – 2015. – № 10.